**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №38 «19» октябрь 2021ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 февралендәге 159-78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №164-80, от 21.05.2020 №168-81, 16.12.2020 №13 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль закон, 2021 елның 01 июлендәге 244-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль закон нигезендә,

**Сарлы авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2020 елның 27 февралендәге 159-78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №164-80, от 21.05.2020 №168-81, 16.12.2020 №13 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 9 статьяда:
а) 10 нчы бүлектә:
түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы, җиденче абзацлар белән тулыландырырга:

«-бюджет керемнәре чыганаклары реестрына беркетелгән керем чыганаклары турында белешмәләр кертү өчен;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән мондый методикага карата гомуми таләпләр нигезендә бюджетка керемнәр керүне фаразлау методикасын раслый;»;

алтынчы абзацны сигезенче абзац дип санарга һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«-бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларда (муниципаль хокукый актларда) билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»;

б) 12 бүлекнең өченче абзацында «бюджет калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

в) 13 өлешнең икенче абзацында «бюджет калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

2) 27 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кредит (облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия, кредит килешүендә (заем килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заем) йөкләмәләрен бирү турында шартнамәдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларыннан максатчан файдалануны үз ягыннан тикшереп торуны башкарырга;

3) 34 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документлар.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы «б», «в» пунктчалары, 3 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай районы Сарлы авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.Р.Шәрипов